# СҮЗ ЯСАЛЫШ ЫСУЛЛАРЫ

Эшләде: Түбән Мәтәскә урта гомуми белем мәктәбенең I квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Габдрахманова Наилә Шайнур кызы

Сүз ясалышы ысуллары дип телнең үз чаралары ярдәмендә яңа сүзләр ясау юлларын, алымнарын атыйлар.

Татар телендә сүз ясалышының түбәндәге ысуллары бар:

- сүз ясагыч кушымча ялгану;
- сүзләр кушылу;
- фонетик ысул;
- сүзләрнең мәгънәсе үзгәрү;
- сүзләрне бер сүз төркеменнән икенчесенә күчерү;
- сүзләрне кыскарту.

# Сүз ясагыч кушымча ялгану ысулы

Сүз – чән
Яз –гы
Татар –ча
Кыш – ын
Уй – ла
Хәйлә – кәр
Сыз - ык

# Сүзләр кушылу ысулы

## Кушма сүзләр

агымсу

тизйөрешле

мөгезборын

## Парлы сүзләр

бала-чага

бәрелә-сугыла

## Тезмә сүзләр

рәсем ясау

туган ил

үги ана яфрагы

# Фонетик ысул

- Авазлар чиратлашу: күз – күр

-Аваз төшеп калу: хәзер – әзер

-Сүзнең басымы күчү: таныш - таныш

-Сүзнең нигезе нечкәрү: чачак -чәчәк

# Сүзләрнең мәгънәсе үзгәрү ысулы

Яңа сүзләр кулланылышта булган сүзләрнең мәгънәләре үзгәреп ясала.

Йомгак(җеп чорнамы) - йомгак(нәтиҗә)
Ай(күк җисеме) – ай(вакыт берәмлеге)
Тамыр(үсемлек өлеше) – тамыр(сүзнең мәгънәле кисәге)

# Сүзләрне бер сүз төркеменнән икенчесенә күчерү ысулы (конверсия ысулы)

Буяу(исем) – буяу(фигыль)

Белдерү (исем) – белдерү(фигыль)

# Сүзләрне кыскарту ысулы

Яңа сүзләр кулланылыштагы тезмә сүзләрне кыскартып ясала.

ТДГПУ
БМО
драмтүгәрәк
турпоход

## Бирелгән сүзләрнең ясалыш ысулын билгеләгез һәм аерып языгыз.

Кушымчалау –
Сүзләр кушылу –
Фонетик –
Күчү –
Мәгънә үзгәрү –
Кыскарту –

Әти-әни, күздә тоту, ярдәмче, үсемлек, кайтаваз, дус –иш, әзер, көтү, киләчәк, агроберләшмә, сарут, дога кылу, теләктәшлек, терекөмеш, Гөлшат, бүлек, кура җиләге, әҗәт, уку, пәрдә.

# Тест

1.Тезмә сүзләр күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

1.җир(җиләге), ял(ит),туган(ил)
2.ара(тирә), аш(су), хатын(кыз)
3.кул(яулык), тере(көмеш), таш(күмер)
4.юл(чы), утын(лык), оял(чан)

2. Кушымчалау юлы белән ясалган сүзләр рәтен билгеләгез.

1.кул(яулык), тере(көмеш), таш(күмер)
2.юл(чы), утын(лык), оял(чан)
3.бакча, бармак, атла
4.туган көн, очкылык тоту, бал корты

3. Фонетик ысул белән ясалган сүзләр рәтен билгеләргә.

1.умартачылык, чынбарлык, ташбаш
2.савыт-саба, бала-чага, тирә-як
3.идән буяу, буяу алу, китап уку, уку дәресе
4. хаҗәт-әҗәт, хикәят-әкият, гамәл-әмәл

4. *Ямьле, комлык, эшлә, озынча* сүзләре нинди ысул белән ясалганнар?

1.сүз ясагыч кушымча өстәү юлы белән
2.сүзләрне кушу юлы белән
3.сүзләрне кыскарту юлы белән
4.сүзгә яңа мәгънә өстәү юлы белән

5. *Ераклыктан* сүзенең нигезен билгеләгез.

1. ерак
2. ераклык
3. ер
4. ераклыкта

6. *Бүлмәдәшне* сүзен сүз төзелеше буенча тикшерегез.

## Җавапларны тикшер:

1. 1
2. 2
3. 4
4. 1
5. 2

Бүл – мә –дәш - не

бүл –тамыр

мә – сүз ясагыч кушымча

дәш - сүз ясагыч кушымча

не – бәйләгеч кушымча